| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 июнь 2016 ел № 3354

Башкарма комитетның 2014 елның 11 декабрендәге 7677 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясе урнаштыруга һәм аны эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидларның хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 11 декабрендәге 7677 номерлы карары белән расланган реклама конструкциясе урнаштыруга һәм аны эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.5. пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата)»;

2) 2.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү, аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла | |

3) 3.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә, гаризаны архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгына (алга таба - идарә башлыгына) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап дүрт көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарә башлыгына җибәрелгән гариза.»;

4) 3.3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. Идарә башлыгы гариза, документларны карап тикшерә һәм идарәнең бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап дүрт көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: идарәнең бүлек белгеченә җибәрелгән гариза.»;

5) 3.3.4 пунктын төшереп калдырырга;

6) 3.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.3. Идарәнең бүлек башлыгы экспертиза үткәрә һәм имзалау өчен идарә башлыгына җибәрә:

- муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проекты;
- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты;
- рөхсәт бирү турында карар проекты.

Процедураларның нәтиҗәсе: муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проекты; муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты; рөхсәт бирү турында карар проекты.»;

7) 3.5.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Идарә башлыгы муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проектын, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын, рөхсәт бирү турында карар проектын карап тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат проектын имзалый;
- муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын имзалый;
- рөхсәт бирү турында карарны имзалый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедура тәмамланган вакыттан башлап ике көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм идарәнең бүлек белгеченә җибәрелгән муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату турында хат, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар яки рөхсәт бирү турында карар.

8) түбәндәге эчтәлектәге 3.8. пункты өстәргә:

«3.8. Техник хаталарны төзәтү.

3.8.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче эш кәгазьләрен алып бару бүлегенә тапшыра:

1) техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

2) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

3)техник хаталар булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып исәпләнгән документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче (вәкаләтле вәкиле) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша, шул исәптән электрон почтадан файдаланып, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша бирелә.

3.8.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны һәм теркәлгән документларны кабул итүне, теркәүне гамәлгә ашыра һәм аларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза.

3.8.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә, карап тикшерү өчен идарә башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен Идарә башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.8.4. Техник хатаны төзәтү турында гариза кергәндә, муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатында әлеге Регламентның 3.3.3., 3.3.4., 3.5. пунктларында каралган процедуралар гамәлгә ашырыла.

Идарә белгече төзәтелгән документны, имза куйдырып, шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, техник хата булган документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен Идарәгә тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хатны почта аша (электрон почта аша) гариза бирүче адресына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза алынганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.»;

9) административ регламеннтка 1 нче кушымтаны, әлеге карарга 1 нче кушымтада каралганча, яңа редакциядә бәян итәргә;

10) әлеге карарга, 2 нче кушымтада каралганча, 6 нчы кушымта өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2016 елның 29 июнендәге
3354 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яр Чаллы
шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма
комитетының 2014 елның 11
декабрендәге 7677 номерлы карары
белән расланган реклама конструкциясе
урнаштыруга һәм аны
эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

| Исполнитель / действие | | Результат |
|---|---|---|
| **Заявитель**<br>Направляет заявление о предоставлении муниципальной услуги в Управление делопроизводством с приложением документов в соответствии с пунктом 2.5 настоящего Регламента | → | Заявление и документы |
| **Специалист Управления делопроизводством**<br>Осуществляет регистрацию заявления, вручает заявителю копию заявления, направляет на рассмотрение Руководителю Исполнительного комитета заявление, документы | → | Принятые, зарегистрированные заявление и документы, направленные Руководителю Исполнительного комитета |
| **Руководитель Исполнительного комитета**<br>Рассматривает заявление и документы, направляет начальнику управления | → | Заявление и документы, направленные начальнику управления |
| **Начальник управления**<br>Рассматривает заявление, документы и направляет специалисту отдела управления | → | Заявление и документы, направленные специалисту отдела управления |
| **Специалист отдела управления**<br>Рассматривает заявление и документы, осуществляет межведомственные запросы и готовит:<br>- проект письма о приостановлении предоставления муниципальной услуги;<br>- проект решения об отказе в предоставлении муниципальной услуги;<br>- проект решения о выдаче | → | Проект письма о приостановлении предоставления муниципальной услуги, проект решения об отказе в предоставлении муниципальной услуги или проект решения о выдаче разрешения, направленные начальнику отдела управления |

разрешения

Начальник отдела управления

Проводит экспертизу и направляет на подпись начальнику управления:
проект письма о приостановлении предоставления муниципальной услуги;
- проект решения об отказе в предоставлении муниципальной услуги;
- проект решения о выдаче разрешения

Проект письма о приостановлении предоставления муниципальной услуги, проект решения об отказе в предоставлении муниципальной услуги или проект решения о выдаче разрешения, направленные начальнику управления

Начальник управления

Рассматривает письмо об отказе в приеме документов, проект Решения об отказе или проект решения о выдаче разрешения и принимает одно из следующих решений:
- подписывает письмо о приостановлении предоставления муниципальной услуги;
- подписывает решение об отказе в предоставлении муниципальной услуги;
- подписывает решение о выдаче разрешения

Специалист отдела управления

Регистрирует и направляет заявителю о приостановлении предоставления муниципальной услуги

Письмо о приостановлении предоставления муниципальной услуги

Специалист отдела управления

Регистрирует и направляет заявителю решение об отказе в предоставлении муниципальной услуги

Решение об отказе в предоставлении муниципальной услуги

Специалист отдела управления

Регистрирует и направляет заявителю решение о выдаче разрешения

Решение о выдаче разрешения

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2016 елның 29 июнендәге
3354 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яр Чаллы
шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма
комитетының 2014 елның 11
декабрендәге 7677 номерлы карары
белән расланган реклама конструкциясе
урнаштыруга һәм аны
эксплуатацияләүгә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
6 нчы кушымта

Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесенә
________________________________
Кемнән: ________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм
____________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)

Язылган: ____________________________________________________________
____________________________________________________________________
Дөрес мәгълүматлар: __________________________________________________
____________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: ______________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
____________________________________________________________________

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль

хезмәт күрсәтү кысаларында шәхси белешмәләрне эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча телефон аша сораштыруда катнашуга ризалыгымны бирәм: __________________.

_______________ ___________________

( __________________)

(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Н.И. Галиева